Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы

КАРАР

“20” ноябрь 2020 ел № 12

«Җир салымы турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 29 номерлы карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 29 номерлы карарының 4 пункты (Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 32 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 25 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 12 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 8 номерлы, 2018 елның 7 ноябрендәге 23 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 30 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 32 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 22 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Ятмас-Дусай авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге
башлыгы: Ф.Х.Гарифуллина